СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2024 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 43-235

с. Татарское Бурнашево

«Бурнаш авыл җирлеге территориясендә җир салымы билгеләү турында»
Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советының
2005нче елның 17нче ноябрендәге 12 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 80 пункты нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советының
карар итте:

1. «Бурнаш авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советының 2005нче елның 17нче ноябрендәге 12 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 һәм 3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары biләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (индивидуаль төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган әлеге пунктта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 %;
3. "Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган

шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата - әлеге пунктта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләренә карата 0,3 %”.

2. «Бурнаш авыл җирлеге территориясендә җир салымы билгеләү турында» Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Советы карары текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Бурнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
ТР Югары Ослан муниципаль районының
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин

Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советының 2024 елның 25 октябрендәге 43-235 номерлы карарына

1 кушымта

Бурнаш авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында

1 статья. Гомуми нигезләмәләр.

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы (алга таба – салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2 статья. Салым ставкалары.

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән җир кишәрлекләренә карата торак пунктларда авыл хуҗалыгы куллану зоналары составында һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3 %;

Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган әлеге пунктта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 %;

3. "Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата - әлеге пунктта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләренә карата 0,3 %;

4. Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 %;

5. Башка җир кишәрлекләренә карата 1.5 %.

Статья 3. Хисап чоры.

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.

4 статья. Салым түләү тәртибе һәм сроклары.

Салым түләүче оешмалар тарафыннан үткән салым чорыннан соң килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча салым түләнергә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килә торган айның 28 числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш.

Статья 5. Салым ташламалары

Салым салудан азат итергә:

1. Гражданнар күмү белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата оешмалар һәм учреждениеләр

2. Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, Бөек Ватан сугышы

инвалидларының һәм сугышында катнашучыларның толл хатыннарының (толларының), 4 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган салым түләүче физик затлар;

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә карата, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары биләгән җир кишәрлекләренә, гомуми файдаланудагы мәйданнарга, урамнарга, юлларга, паркларга, аллеяларга, яшел утыртмаларга, һәйкәлләргә, бәйрәм чараларын уздыру урыннарына, спорт объектларына һәм гомуми файдаланудагы башка объектларга карата оешмалар һәм учреждениеләр.

Җирле бюджеттан финанслана торган бюджет учреждениеләре биләгән җир кишәрлекләренә карата, әлеге карарның 2 статьясындагы 1, 2, 3, 4 пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, 0,6% киметелгән салым ставкасын куллану рәвешендә җир салымы түләү буенча ташлама бирергә.

Гомуми файдаланудагы 1-3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05% киметелгән салым ставкасын куллану рәвешендә җир салымы түләү буенча ташлама бирергә.

Бюджет учреждениеләре тарафыннан Республика һәм Федераль бюджетлардан финанслана торган җир кишәрлекләренә карата, әлеге карарның 2 статьясындагы 1, 2, 3, 4 пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, салымның киметелгән ставкасын 1% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташлама бирергә.

Совет рәисе,
ТР Югары Ослан муниципаль районының
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин